**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

11 август 2025 ел номер 1499

# КАРАР

## «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» акциясен оештыру һәм уздыру турында

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә яшәүче аз керемле гаиләләрдән булган балаларга, тәрбиягә алынган балаларга, инвалид балаларга һәм күпбалалы гаиләләргә адреслы социаль ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының беренче сыйныф укучылары балаларына уку елы башлануга социаль ярдәм чараларын булачак беренче сыйныф укучыларына портфельләр һәм мәктәп кирәк-яраклары тапшыру рәвешендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Мәктәптән тыш эш үзәге» ӨББ МБУ (Шастина М. Д.) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» акциясен оештыруга һәм уздыруга вәкаләтле башкарма органы итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МКУны (Хөсәенова Л. И.) гаризаларда күрсәтелгән белешмәләрнең һәм мөрәҗәгать итүче (аның вәкаләтле вәкиле) тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген тикшерү өчен җаваплы итеп билгеләргә..

4. Лаеш муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары директорларына авыл җирлеге башлыгы тарафыннан расланган ярдәмгә мохтаж булачак беренче сыйныф укучыларының гаиләләре исемлеген тапшырырга.

5. Акция үткәрү өчен акчалар тотуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБУнең бюджеттан тыш шәхси счетына иганәчелек ярдәме кертү исәбенә гамәлгә ашырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А. Г. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**